| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» 11 2022 ел № 324

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын тукландыруны оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарына (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

Укучыларны балансслы кайнар ризык белән тәэмин итү, аларның сәламәтлеген саклау, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декарендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.3/2.4.3590-20 СанПиН таләпләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 79 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 299-ФЗ номерлы Федераль закон белән, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениеләрендә белем алучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын туклландыруны оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: гомуми белем бирү оешмасы өйдә укыту оештырылган, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны бушлай ике тапкыр туклануны акчалата компенсациягә алыштыру рәвешендә бушлай туклану белән тәэмин итә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.С.Галимуллин